РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 04.02.2026 131 **КАРАР**

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында исәпләүләр тәртибен раслау турында» 2020 елның 10 июнендәге 471 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль законның 65 статьясының 2 нче өлеше нигезендә, шулай ук Алабуга муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль бюджет мәктәпкәчә мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган аерым категория гражданнарга өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында исәпләүләр тәртибен раслау турында» 2020 елның 10 июнендәге 471 номерлы карары белән расланган, Алабуга муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвен формалаштыру һәм алу тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 1.3 пунктындагы 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Аерым категория хезмәткәрләр өчен закон тарафыннан билгеләнгән, эш вакытының нормаль озынлыгы шартларында төп эш урыны буенча эшләүче гаиләләргә, әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы 5-7 абзацларында каралган ташлама бирелә».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Э.Р. Әхмәдиева

Лист согласования к документу № 131 от 04.02.2026
Инициатор согласования: Шарифуллина З.Р. Секретарь
Согласование инициировано: 04.02.2026 11:22

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано 04.02.2026 - 11:36 | - |